ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.02.2016 г.Казань № 19

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмә раслау хакында” 09.09.2015, № 111 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче затлар һәм бүтән затлар тарафыннан вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 650 номерлы Указы нигезендә

б о е р а м:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының “Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт

тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмә раслау хакында” 09.09.2015, № 111 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 пунктның “б” пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“дәүләт хезмәткәренә вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү”;

17 пунктта дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

19 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 19.1 пунктын өстәргә:

“19.1. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән белдерүнамә Дәүләт комитетының белдерүнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерли торган кадрлар һәм юридик эш секторы тарафыннан карап тикшерелә.”;

түбәндәге эчтәлекле 19.2 пунктын өстәргә:

“19.2. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән белдерүнамәне, яки Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында һәм “д” пунктчасында күрсәтелгән белдерүнамәләрне карап тикшерү нәтиҗәсендә нигезле бәяләмә әзерләгәндә Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторындагы коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы булган вазифаи заты мөрәҗәгать яки белдерүнамә тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә, аннан язмача аңлатмалар алырга, ә Дәүләт комитеты рәисе яки Дәүләт комитеты рәисенең моңа махсус вәкаләт алган урынбасары дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрергә хокуклы. Мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерүнамә килгән көннән башлап җиде эш көне дәвамында Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка төрле материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерүнамә килгән көннән алып 45 көн дәвамында тапшырыла. Күрсәтелгән чор озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыгракка түгел.”;

20 пунктның “а” пунктчасын түбәндәгечә бәян итәргә:

“а) 10 көнлек чорда Комиссия утырышының көнен билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышының көне, Нигезләмәнең 21 һәм 22 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат килгән көннән башлап 20 көннән соңга калып билгеләнә алмый;”;

21 пункттагы “өченче абзацта күрсәтелгән гаризаны” сүзләрен “өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризаларны” сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“23. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше хакында мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасын биләүче граждан катнашында үткәрелә. Дәүләт хезмәткәре яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасын биләүче граждан Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә күрсәтә.”;

түбәндәге эчтәлекле 23.1 пунктын өстәргә:

“23.1. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәреннән яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасын биләүче гражданнан башка да үткәрелә ала, түбәндәге очракларда:

а) әгәр дә Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә дәүләт хезмәткәренең яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасын биләүче гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәсә;

б) әгәр дә Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм тиешле рәвештә аның үткәрелү вакыты һәм урыны турында хәбәр алган дәүләт хезмәткәре яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасын биләүче граждан Комиссия утырышына килмәсә.”;

түбәндәге эчтәлекле 30.1 пунктын өстәргә:

“30.1. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгының булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазифаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлыкның мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) Дәүләт комитеты рәисенә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки аның барлыкка килүенә юл куймау буенча чаралар күрү турында киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата аерым бер җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.”;

32 пунктта “26-31 пунктларда” сүзләрен “26-31 һәм 33 пунктларда” сүзләренә алмаштырырга;

40 пунктта “3 көнлек чорда” сүзләрен “7 көнлек чорда” сүзләренә алмаштырырга.

Рәис С.Е.Иванов